**Вахит ИМАМОВ,**
*язучы, 1997-2015 елларда Татарстан Язучылар берлегенең Яр Чаллы оешмасы рәисе*

# ШИФАЛЫ ҺӘМ БӘРӘКӘТЛЕ «ЛӘЙСӘН»

...1963 елда нигезләнеп киткән «Ләйсән» түгәрәге никадәрле талантларга канат ярып биргән!

Кырык биш ел дәвамында «Ләйсән» берләшмәсе белән егермегә якын әдип җитәкчелек итте. Әдәбиятның кадере бар заманнарда Факил Сафин, Айдар Хәлим, Рәшит Бәшәр кебек җитәкчеләренә шәһәр казнасыннан хезмәт хакы түләтүгә ирешкән чакларыбыз да булгалады. «Ләйсән» бүген фидаи җаннар, фидакарьләр хисабына гына сүнми яши әле. Ә югыйсә...

Казан дәүләт университетындагы «Әллүки»дән кала, республикада «Ләйсән» шикелле татар әдәбиятын баеткан башка бер генә берләшмә да юк шикелле. Чаллыдан Казанга күчеп киткәннәрне һәм инде вафат булырга өлгергән язучыларны саный башласаң, «Ләйсән» берләшмәсе татар әдәбиятына алтмышка якын шагыйрь һәм прозаикны бүләк иткән инде. Арада Мөдәррис Әгъләмов, Разил Вәлиев шикелле Тукай бүләгенә, Рахмай Хисмәтуллин, Айдар Хәлим, Факил Сафин, Вахит Имамов, Рәшит Бәшәр кебек Исхакый яисә Алиш премиясенә лаек булганнары да бар. Кадыйр Сибгатуллин, Газиз Кашапов, Альберт Сафин, Нәҗип Мадьяров кебек лаеклылар тагын да бар иде, ни кызганыч, алар бүләк-хөрмәт дигәннәрен татырга өлгерә алмый китте.

Ләйсән – кешелекнең иң көтеп алынган яңгыры бит. «Ләйсән» берләшмәсенең иҗат тамчылары һәм иҗат чишмәсе дә һәрвакытта сагындыргыч, бәрәкәтле һәм шифалы булсын!

*«Ләйсән» – моңлы бишегебез» Чаллы шәһәре Язучылар оешмасы каршында эшләп килүче «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенең 45 еллык юбилее уңаеннан төзелгән күмәк җыентыгы / Төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе. – 2009. – Б.3-4.*